**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 15 апрель | № 225

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче, 2016 ел, 24 февраль, 112 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасында яшәүнең сыйфатын күтәрү һәм гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү.<br>2. Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм тәэмин итү.<br>3. Татарстан Республикасы халкына социаль ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү. |

| | |
|---|---|
| | 4. Үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә кимчелекләр булган балаларны тәрбияләүче гаиләләрне озата бару буенча ведомствоара багланышлар механизмын булдыру.<br>5. Гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә булышлык күрсәтү, ныгыту һәм яклау, гаиләләрнең тормыш сыйфатын күтәрү.<br>6. Татарстан Республикасында инвалидларның һәм халыкның башка аз мобиль төркемнәренең яшәү эшчәнлегендә өстенлекле өлкәләрдә хезмәтләр күрсәтүнең һәм өстенлекле объектларның һәркем файдалана алырлык булу дәрәҗәсен күтәрү.<br>7. Татарстан Республикасында инвалидлары тернәкләндерү һәм социаль яраклаштыру системасын мәгълүмати-методик һәм кадрлар белән тәэмин итү.<br>8. Татарстан Республикасында җәмгыятьтәге социаль таркаулыкны җиңеп чыгу һәм инвалидлар мәсьәләләренә һәм инвалидлар һәм халыкның башка аз мобиль төркемнәре өчен терекле эшчәнлегенең уңай мохитын тәэмин итү мәсьәләләренә карата уңай мөнәсәбәт булдыру.<br>9. Өч яшькә кадәр балаларның тормышы һәм сәламәтлеге сыйфатын күтәрү.<br>10. Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны тәрбиягә гаиләгә урнаштыру өчен уңай шартлар тудыру.<br>11. Инвалид бала 18 яшькә җиткәч аны мөстәкыйль тормышка әзерләү максатында аның потенциалын максималь үстерү.<br>12. Энергия саклау чараларын тормышка ашыру, энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү, ягулык-энергетика ресурсларыннан файдалануны оптимальләштерү һәм, оештыру, икътисадый, фәнни-техник шартлар һәм энергия ресурсларыннан югары нәтиҗәле файдалануны тәэмин итүче башка шартлар тудыру нигезендә, кулланыла торган энергия ресурсларына чыгымнарны киметү хисабына ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны тәэмин итү»; |

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | 1. 2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр».<br>2. 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның яшәү сыйфатын күтәрү».<br>3. 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне яңарту һәм үстерү».<br>4. «2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронаж тәэмин итеп тору системасын |

| | |
|---|---|
| | формалаштыру комплексы программасы».<br>5. 2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисади хәлен яхшырту».<br>6. 2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит».<br>7. 2014 елга «Бәләкәч - Малыш».<br>8. 2014 елга «Опекуннарга һәм тәрбиягә алган әти-әниләргә дәүләт ярдәме күрсәтү»<br>9. «2016 – 2017 елларга Татарстан Республикасында актив мөстәкыйль тормышта тереклек эшчәнлеге алып баруда сизелерлек бозулары булган балаларны комплекслы әзерләү һәм социаль яраклаштыру буенча ведомствоара программа»;<br>10. «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү». |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
Программаны финанслауның гомуми күләме 171 436 444,744 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән –127 633 169,178 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 43 756 971,6 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 25 126,9 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (2013 елда Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган калган акча) – 21 177,066 мең сум, алардан 1 654,537 мең сум – 2013 елда алынган акчаның калган өлеше. .
<br><br>
(мең сум)
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td rowspan="2">Финанслау күләме – барлыгы</td><td colspan="4">Шул исәптән</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td><td>федераль бюджет акчасы</td><td>Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия</td><td>бюджеттан тыш акча</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>20 908 005,515</td><td>15 441 582,078</td><td>5 450 597,7</td><td>14 171,2</td><td>1 654,537</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>23 049 546,7</td><td>17 160 913,8</td><td>5 877 677,2</td><td>10 955,7</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>23 988 991,266</td><td>17 909 996,1</td><td>6 069 310,8</td><td>-</td><td>9 684,366</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>24 337 702,063</td><td>18 132 505,8</td><td>6 195 358,1</td><td>-</td><td>9 838,163</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>25 369 288,7</td><td>18 907 530,2</td><td>6 461 758,5</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>26 404 974,0</td><td>19 678 283,1</td><td>6 726 690,9</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>27 377 936,5</td><td>20 402 358,1</td><td>6 975 578,4</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>171 436 444,744</td><td>127 633 169,178</td><td>43 756 971,6</td><td>25 126,9</td><td>21 177,066</td></tr>
</table>
<br>
Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен
</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | тәгаенләнергә тиеш»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«инвалид балалар өчен махсуслашкан биш оешмада тәрбияләнүче тереклек эшчәнлегендә ачык күренеп торган бозулар булган 10 яшьтән 18 яшькә кадәр инвалид балаларны көнкүрештә үзенә үзе хезмәт күрсәтүгә һәм көченнән килгәнчә хезмәткә әзерлек буенча укыту белән тәэмин итү: 2016 елда – 210 кеше, 2017 елда – 215 кеше;

инвалид балалар өчен махсуслашкан биш оешмада тәрбияләнүче инвалид балаларның гомуми санында инвалид балалар өчен махсуслашкан биш оешмада тәрбияләнүче тереклек эшчәнлегендә ачык күренеп торган бозулар булган көнкүрештә үзенә үзе хезмәт күрсәтүгә һәм көченнән килгәнчә хезмәткә әзерлек алган инвалид балаларның чагыштырма авырлыгын 2016 елда – 27 процентка, 2017 елда – 28 процентка кадәр җиткерергә;

инвалид балалар өчен махсуслашкан биш оешмада тәрбияләнгән, мөстәкыйль яшәүчеләргә аларга 18 яшь тулганнан соң бер ел дәвамында социаль ярдәм тәэмин итәргә: 2016 елда – 39 кешегә, 2017 елда – 43 кешегә»;

Программаның I бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Инвалид балаларны мөстәкыйль тормышка әзерләү мәсьәләсе акылы зәгыйфь балалар өчен интернат йортларда тәрбияләнүче һәм интернат мәктәпләрдәге балалар өчен актуаль, чөнки мондый балаларның 70 проценттан артыгы саклау потенциалына ия, укый, элементар хезмәт күнекмәләрен үзләштерә һәм җәмгаятькә файдалы була алалар.

Бүген Татарстан Республикасында инвалид балалар өчен 14 оешма эшли (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 12 интернат мәктәбе һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, эәш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының акылы зәгыйфь балалар өчен ике балалар интернат йорты).

Инвалид балаларның физик һәм менталь бозылулары никадәр күбрәк булса, элементар мөстәкыйльлек күнекмәләре шулкадәр азрак үсеш ала, чөнки интернат шартларында балалар өчен көндәлек эшләрнең күпчелек өлешен персонал башкара, нәтиҗәдә балаларның мөстәкыйль яшәү өчен җитәрлек күнекмәләре булмый һәм алар иждивенлык позициясендә була. Бу фактлар алга таба һөнәри белем алуда һәм эшкә урнашуда, мөстәкыйль яшәүне оештыруда авырлыкларга китерә.

Бу өлкәдәге хәлне инвалид балаларны тернәкләндерү һәм яраклаштыру, аларга адекват һөнәри юнәлеш сайлау һәм хезмәт күнекмәләренә өйрәтү буенча чараларны, шулай ук инвалид балаларның альтернатив коммуникациясен, социаль һәм әйләнә-тирәгә яраклашуын, һөнәри юнәлештә консультация бирүне, аларның социаль һәм хезмәткә ярашуын, мөстәкыйль тормышка әзерлеген үз эченә алган комплекслы программаларны тормышка ашыру юлы белән шактый яхшыртырга мөмкин.

Бүген социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшчәнлеге практикасына заманча технологияләрне кертүнең нәтиҗәле ысулы булып Тормышта авыр хәлдә калган

балаларга булышлык күрсәтү фонды (алга таба – Фонд) ярдәмен алган төбәк программаларын тормышка ашыру тора.

Татарстан Республикасы 2009 елдан башлап социаль партнерлык кысаларында Фонд белән актив хезмәттәшлек итә, ул тормышта авыр хәлдә калган балаларны яклауның тугыз инновацион социаль технологияләрне гамәлгә кертү өчен республикага 61 100,0 мең сумнан артык акча инвестицияләде.

Бүген республиканың инвалид балалар өчен махсуслашкан биш оешмасында («Акылы зәгыйфь балалар өчен Югары-Утар балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, «Акылы зәгыйфь балалар өчен Дәрвишләр Бистәсе балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, «Е.Г.Ласточкина ис. I – II төрдәге Казан махсус (коррекцион) гомуми белем бирү интернат мәктәбе» сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен дәүләт бюджет махсус (коррекцион) белем бирү учреждениесе, «7 нче V төрдәге Казан махсус (коррекцион) гомуми белем бирү интернат мәктәбе» сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен дәүләт бюджет махсус (коррекцион) белем бирү учреждениесе, «4 нче VI төрдәге Казан махсус (коррекцион) гомуми белем бирү интернат мәктәбе» сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен дәүләт бюджет махсус (коррекцион) белем бирү учреждениесе) 700 дән артык инвалид бала яши, аларның 20 проценты тирәсе – ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар.

Әлеге оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең өчтән икесендә, шулай ук «Республика сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – РСНКСТҮ) йөрүче инвалид балаларда мөстәкыйльлекне үстерү потенциалы булганлыкны исәпкә алсак, менталь бозылулары булган, сукыр һәм начар күрүче, саңгырау һәм начар ишетүче, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган һәм авыр сөйләм кимчелекле 18 яшькәчә инвалид балаларның социаль җайлашу потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру республиканың социаль хезмәт күрсәтү тармагын һәм мәгариф системасын үстерүнең стратегик юнәлешләренең берсе булырга тиешлек факты ачык күренә.

Бу мәсьәләне хәл итүне 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының яңа «2016 – 2017 елларга Татарстан Республикасында актив мөстәкыйль тормышта тереклек эшчәнлеге алып баруда сизелерлек бозулары булган балаларны комплексны әзерләү һәм социаль яраклаштыру буенча ведомствоара программа» яңа ярдәмче программа кысаларында гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – ТР ХЭТИһСЯМ), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – ТР МһФМ) һәм ведомстводагы учреждениеләр башкара.

Ярдәмче программа югарыда санап кителгән акылы зәгыйфь балалар өчен балалар интернат йортлары, интернат мәктәпләр һәм РСНКСТҮ базасында (алга таба – нигез мәйданчыклар) тормышка ашырылачак, чаралар төрле дәрәҗәдә сәламәтлекләре чикләнгән балаларны: менталь бозылулары булган, начар күрүче һәм

начар ишетүче, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган һәм авыр сөйләм кимчелекле балаларны (алга таба максатчан төркемдәге балалар) колачлаячак.

Нигез мәйданчыклар тернәкләндерү ярдәменең барлык төрләре сыйфатын шактый арттырырга, балаларның әлеге категорияләренең җайлашу потенциалын объектив бәяләргә һәм балаларны мөстәкыйль тормышка әзерләүнең нәтиҗәле программасын төзергә мөмкинлек бирә торган заманча тернәкләндерү җиһазлары белән җиһазланачак.

Ярдәмче программа экспертиза үтте һәм Фонд идарәсе тарафыннан аңа финанслар белән булышу һәм 2016 елда 9 684 366 (тугыз миллион алты йөз сиксән дүрт мең өч йөз алтмыш алты) сум акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде(2015 елның 20 октябрендәге 5 нче утырыш беркетмәсе). 2017 елга 9 838 163 (тугыз миллион сигез йөз утыз сигез мең йөз алтмыш өч) сум күләмдә акчага гариза бирелгән.

Бергәләп финанслау Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, фонд һәм грант алучы (Татарстан Республикасы психологлары ассоциациясе) арасында төзелгән Ярдәмче программаны үтәүгә грант рәвешендә акча бүлү турында килешү (алга таба – Килешү) нигезендә гамәлгә ашырылачак.»;

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Бүгенге көндә халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәлдәге законнар һәм билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә гражданнарның социаль гарантияләрен, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль ярдәм күрсәтүне тормышка ашыру Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып тора.

Моннан тыш, җәмгыятьтә гаилә, бала, җаваплы ата-ана кыйммәтләрен булдыру, начар гаиләне вакытында танып алуга, авыр тормыш хәлендә калган гаиләгә ведомствоара нигездә күрсәтелә торган индивидуальләштерелгән адекват ярдәмгә нигезләнгән профилактикалауны тәэмин итү, баланы туган гаиләсендә тәрбияләү өстенлеге, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр санын киметү, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү очраклары кимүгә, «куркынычлылык төркеме»нә керә торан гаиләләрне билгеләүгә, аларга социаль ярдәм күрсәтү һәм тернәкләндерүгә, гаиләләрдә балаларга мәрхәмәтсез мөнәсәбәт очраклары санын киметүгә, ата-ана каравыннан мәхрүм калучы балалар санын киметүгә ярдәм итәчәк нәтиҗәле механизмнар булдыру аеруча актуаль булып тора.

Программаның максаты социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәле адреслы системасын төзү, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренең яшәү сыйфатын күтәрү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларын хәл итү күздә тотыла:

Татарстан Республикасы гражданнарның аерым категорияләренең яшәү сыйфатын күтәрү һәм аларга социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү;

өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы халкына социаль ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү;

үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне тәэмин итеп тору буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү механизмын булдыру;

гаиләгә һәм гаилә тормышы кыйммәтләренә булышлык күрсәтү, аларны ныгыту һәм саклау, гаиләләрнең яшәү сыйфатын күтәрү;

Татарстан Республикасында инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре тормышында өстенлекле объектлардан һәм өстенлекле тармаклардагы хезмәтләрдән файдалана алу дәрәҗәсен күтәрү;

Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү һәм социаль интеграция системасын мәгълүмати-методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү;

Татарстан Республикасында җәмгыятьтәге социаль таркаулыкны җиңеп чыгу һәм инвалидлар мәсьәләләренә карата вә инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнүче башка төркемнәре өчен яшәүнең уңайлы мохитен тәэмин итү мәсьәләләренә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру;

өч яшькәчә балаларның яшәү сыйфатын һәм сәламәтлеген яхшырту;

ятим балалар һәм әти-әни каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру;

оештыру, икътисадый, фәнни-техник һәм энергия ресурсларын югары нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә торган башка шартлар булдыру нигезендә энергия саклау чараларын тормышка ашыру, энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү, ягулык-энергетика ресурсларын куллануны оптимальләштерү һәм кулланыла торган энергия ресурсларына чыгымнарны киметү хисабына ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны тәэмин итү;

инвалид баланы аңарга 18 яшь тулганнан соң мөстәкыйль яшәүгә әзерләү максатында аның потенциалын максималь үстерү.

Әлеге максат һәм бурычларга ирешү тормышка ашыру каралган ун ярдәмче программа кысаларында гамәлгә ашырылачак:

2014 – 2020 елларга «Социаль түләүләр»;

2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның яшәү сыйфатын күтәрү»;

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне яңарту һәм үстерү»;

«2014 елга үсешләрендә һәм сәламәтлекләрендә тайпылышлар булган балалар тәрбияләүче гаиләләрне яшәү урыны буенча ведомствоара патронаж тәэмин итеп тору системасын формалаштыру комплекслы программасы»;

2015 – 2020 елларга «Гаиләләрнең социаль-икътисади хәлен яхшырту»;

2014 – 2015 елларга «Уңайлы мохит»;

2014 елга «Бәләкәч - Малыш»;

2014 елга «Опекуннарга һәм тәрбиягә алган әти-әниләргә дәүләт ярдәме күрсәтү»;

«2016 – 2017 елларга Татарстан Республикасында актив мөстәкыйль тормышта тереклек эшчәнлеге алып баруда сизелерлек бозулары булган балаларны комплекслы

әзерләү һәм социаль яраклаштыру буенча ведомствоара программа»;

«Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү».

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турында мәгълүматлар ярдәмче программалар яссылыгында әлеге Программага 1 нче кушымтада китерелә.

Программаны тормышка ашыру вактылары: 2014 – 2020 еллар.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 171 436 444,744 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 127 633 169,178 мең сум; федераль бюджет акчасы исәбеннән – 43 756 971,6 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 25 126,9 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан (2013 елда Тормышта авыр хәлдә калган балаларга ярдәм күрсәтү фондыннан алынган калган акча) – 21 177,066 мең сум, алардан 1 654,537 мең сум – 2013 елда алынган акчаның калган өлеше. .

(мең сум)

| Ел | Финанслау күләме – барлыгы | Шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | федераль бюджет акчасы | Россия Федера-циясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия | бюд-жеттан тыш акча |
| 2014 | 20 908 005,515 | 15 441 582,078 | 5 450 597,7 | 14 171,2 | 1 654,537 |
| 2015 | 23 049 546,7 | 17 160 913,8 | 5 877 677,2 | 10 955,7 | - |
| 2016 | 23 988 991,266 | 17 909 996,1 | 6 069 310,8 | - | 9 684,366 |
| 2017 | 24 337 702,063 | 18 132 505,8 | 6 195 358,1 | - | 9 838,163 |
| 2018 | 25 369 288,7 | 18 907 530,2 | 6 461 758,5 | - | - |
| 2019 | 26 404 974,0 | 19 678 283,1 | 6 726 690,9 | - | - |
| 2020 | 27 377 936,5 | 20 402 358,1 | 6 975 578,4 | - | - |
| Барысы | 171 436 444,744 | 127 633 169,178 | 43 756 971,6 | 25 126,9 | 21 177,066 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Программаны ресурслар белән тәэмин итү буенча җентекле мәгълүмат әлеге Программага 2 нче кушымтада китерелгән»;

Программага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәләләр);

2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне яңарту һәм үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 28 766 681,548 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 28 743 469,348 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 23 212,2 мең сум:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Финанслау күләме – барлыгы</th><th colspan="2">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Россия Федера-циясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>3 135 663,92</td><td>3 121 792,02</td><td>13 871,9</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>3 664 545,5</td><td>3 655 205,2</td><td>9 340,3</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>3 944 328,924</td><td>3 944 328,924</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>4 145 371,104</td><td>4 145 371,104</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>4 447 030,08</td><td>4 447 030,08</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>4 629 321,77</td><td>4 629 321,77</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>4 800 420,25</td><td>4 800 420,25</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>28 766 681,548</td><td>28 743 469,348</td><td>23 212,2</td></tr>
</table>
Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

Ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 28 766 681,548 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 28 743 469,348 мең сум, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия исәбеннән – 23 212,2 мең сум:

(мең сум)

| Ел | Финанслау күләме – барлыгы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидия |
| 2014 | 3 135 663,92 | 3 121 792,02 | 13 871,9 |
| 2015 | 3 664 545,5 | 3 655 205,2 | 9 340,3 |
| 2016 | 3 944 328,924 | 3 944 328,924 | - |
| 2017 | 4 145 371,104 | 4 145 371,104 | - |
| 2018 | 4 447 030,08 | 4 447 030,08 | - |
| 2019 | 4 629 321,77 | 4 629 321,77 | - |
| 2020 | 4 800 420,25 | 4 800 420,25 | - |
| Барысы | 28 766 681,548 | 28 743 469,348 | 23 212,2 |

Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш»;

Ярдәмче программага 1 нче кушымтада:

«Халыкка социаль ярдәм күрсәтүче дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкка социаль ярдәм күрсәтүче дәүләт оешмалары эшчәнлеген тәэмин итү»;

15 графада «3 798 346,2 ТРБ» сүзләрен «3 679 942,924 ТРБ» сүзләренә алмаштырырга;

16 графада «2 493 890,2 ТРБ» сүзләрен «2 375 486,924 ТРБ» сүзләренә алмаштырырга;

«Ярдәмче программа буенча барысы, шул исәптән:» юлында:

15 графада «4 062 732,2» саннарын «3 944 328,924» саннарына алмаштырырга;

16 графада «4 263 774,38» саннарын «4 145 371,104» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлында:

15 графада «4 062 732,2» саннарын «3 944 328,924» саннарына алмаштырырга;

16 графада «4 263 774,38» саннарын «4 145 371,104» саннарына алмаштырырга;

Программага «2016 – 2017 елларга Татарстан Республикасында актив мөстәкыйль тормышта тереклек эшчәнлеге алып баруда сизелерлек бозулары булган балаларны комплекслы әзерләү һәм социаль яраклаштыру буенча ведомствоара программа» ярдәмче программасын өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков